ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Физик культура һәм спорт турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 29 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 3, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2020, № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш), № 34 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 1 пунктында «мәктәп спорт лигалары,» сүзләреннән соң «һәвәскәр спорт лигалары,» сүзләрен өстәргә;

2) 6 статьяның 1 өлешендәге $4^2$ пунктында «массакүләм спортны,» сүзләрен «массакүләм спортны үстерү һәм аннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү,» сүзләренә алмаштырырга;

3) 9 статьяда:
а) 2 өлештә «Физкультура-спорт оешмалары» сүзләреннән соң «спорт төрләрен үстерүдә,» сүзләрен өстәргә;
б) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:
«$2^1$. Физкультура-спорт оешмаларына федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә тиешенчә федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле

бюджетлар бюджет ассигнованиеләре исәбеннән финанс ярдәме һәм башка ярдәм күрсәтелергә мөмкин.»;

4) түбәндәге эчтәлекле $12^2$ статья өстәргә:

«$12^2$ статья. **Һәвәскәр спорт өлкәсендәге эшчәнлекне җайга салу үзенчәлекләре**

Һәвәскәр спорт өлкәсендәге эшчәнлекне җайга салу үзенчәлекләре Федераль закон белән билгеләнә.»;

5) 14 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Спорт судьяларының квалификация категорияләрен бирү, аларны раслау, алардан мәхрүм итү һәм аларны кире кайтару тәртибе, спорт судьяларының тиешле категорияләрен бирү өчен квалификация таләпләренең эчтәлеге, шулай ук спорт судьяларының хокуклары һәм бурычлары федераль законнар нигезендә раслана торган Спорт судьялары турында нигезләмә белән билгеләнә.»;

6) 20 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:

«$1^1$. Эш бирүчеләр эш урыны буенча физкультура-спорт клубларын үстерүгә, шулай ук хезмәткәрләрне физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүгә җәлеп итү һәм аларда сәламәт яшәү рәвеше алып бару ихтыяҗын формалаштыру максатларында хезмәткәрләрнең физкультура чараларында һәм (яисә) спорт ярышларында катнашуына ярдәм итәргә хокуклы.»;

б) 3 өлештә «җәлеп итү» сүзләреннән соң «, оештырылган һәм (яисә) мөстәкыйль дәресләр үткәрү һәм (яисә) аларны үткәрүгә һәм (яисә) физик культура чараларында һәм спорт ярышларында (һәвәскәр спорт ярышларын да кертеп) катнашуга мөмкинлекләр тудыру» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 12 апрель
№ 16-ТРЗ

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ